**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3370**
**25.04.2023**

Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8501 номерлы карары белән расланган җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 25 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 76-ТРЗ номерлы Законы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8501 номерлы карары белән расланган җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.3.1 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) гариза бирүчене индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (өй янындагы җир участогы), үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен җир участогы алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертү турында карар (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

2) 2.4.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Гариза бирүчене индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (өй янындагы җир участогы), үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен җир участогы алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертү турында карар кергән көннән башлап 30 көн эчендә кабул ителә.

Гражданнарга индивидуаль торак төзелешен, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелекне гамәлгә ашыру өчен сатуларсыз җир участогы бирү чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Җир участогын бирү турындагы карар җир участогын сайлау акты нигезендә, аны имзалаган вакыттан башлап 14 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.»;

3) 2.6.1 пунктның 9 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

4) 3.3.1.1 пунктның унберенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан запросның электрон формасының һәр кырын тутыру процессында, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал, запросның электрон формасының дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, турыдан-туры запросның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

5) 3.5.2 пунктның җиденче абзацында, 3.5.3 пунктның алтынчы абзацында «бакчачылык яки яшелчәчелек» сүзләренә «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов